# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**Муниципаль районнарның һәм "Чаллы шәһәре" шәһәр округының җирле үзидарә органнарына хайваннар чирләрен кисәтү һәм бетерү, аларны дәвалау, кеше һәм хайваннар өчен уртак чирләрдән халыкны яклау чараларын үткәрүне оештыру өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2011 елның 29 декабрендә
кабул ителде

Әлеге Закон "Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә муниципаль районнарның һәм "Чаллы шәһәре" шәһәр округының җирле үзидарә органнарына (алга таба – җирле үзидарә органнары) хайваннар чирләрен кисәтү һәм бетерү, аларны дәвалау, кеше һәм хайваннар өчен уртак чирләрдән халыкны яклау чараларын үткәрүне оештыру өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирә.

1 статья. **Җирле үзидарә органнарына бирелә торган дәүләт вәкаләтләре**

1. Җирле үзидарә органнарына хайваннар чирләрен кисәтү һәм бетерү, аларны дәвалау, кеше һәм хайваннар өчен уртак чирләрдән халыкны яклау чараларын үткәрүне оештыру өлкәсендә Татарстан Республикасының түбәндәге дәүләт вәкаләтләре (алга таба – дәүләт вәкаләтләре) бирелә:

1) мал-туарның түләмә чире каберлекләрен һәм биотермик чокырларны (алга таба – объектлар) гамәлдәге законнар нигезендә карап тоту, шул исәптән аларны төзекләндерү, тиешле санитар халәткә китерү;

2) объектларның иминлеген тәэмин итү чараларын күрү;

3) биотермик чокырларны консервацияләү.

2. Җирле үзидарә органнарына дәүләт вәкаләтләре бирелә торган объектлар исемлеге Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана.

2 статья. **Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарына дәүләт вәкаләтләре бирелә торган муниципаль берәмлекләр исемнәре**

Әлеге Закон нигезендә дәүләт вәкаләтләре Татарстан Республикасында түбәндәге муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына бирелә:

"Чаллы шәһәре", Әгерҗе муниципаль районы, Азнакай муниципаль районы, Аксубай муниципаль районы, Актаныш муниципаль районы, Алексеевск муниципаль районы, Әлки муниципаль районы, Әлмәт муниципаль районы, Апас муниципаль районы, Арча муниципаль районы, Әтнә муниципаль районы, Баулы муниципаль районы, Балтач муниципаль районы, Бөгелмә муниципаль районы, Буа муниципаль районы, Югары Ослан муниципаль районы, Биектау муниципаль районы, Чүпрәле муниципаль районы, Алабуга муниципаль районы, Зәй муниципаль районы, Зеленодольск муниципаль районы, Кайбыч муниципаль районы, Кама Тамагы муниципаль районы, Кукмара муниципаль районы, Лаеш муниципаль районы, Лениногорск муниципаль районы, Мамадыш муниципаль районы, Менделеевск муниципаль районы, Минзәлә муниципаль районы, Мөслим муниципаль районы, Түбән Кама муниципаль районы, Яңа Чишмә муниципаль районы, Нурлат муниципаль районы, Питрәч муниципаль районы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Саба муниципаль районы, Сарман муниципаль районы, Спас муниципаль районы, Тәтеш муниципаль районы, Тукай муниципаль районы, Теләче муниципаль районы, Чирмешән муниципаль районы, Чистай муниципаль районы, Ютазы муниципаль районы.

3 статья. **Дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен җирле үзидарә органнарына тапшырыла торган матди чаралар**

1. Татарстан Республикасы милкендәге матди чаралар, әлеге Законда каралган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны тәэмин итү зарурлыгы булган очракта, Тапшырыла торган матди чаралар исемлеге нигезендә җирле үзидарә органнарына түләүсез файдалануга тапшырыла.

2. Тапшырыла торган матди чаралар исемлеген эшләү, аны раслау, матди чараларны тапшыру турында карар кабул итү, җирле үзидарә органнары тәкъдимнәрен исәпкә алып, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең ветеринария эше өлкәсендә вәкаләтле органы тарафыннан әзерләнгән мөрәҗәгать нигезендә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мөлкәт мөнәсәбәтләре өлкәсендә вәкаләтле органы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

4 статья. **Җирле үзидарә органнарына бирелә торган дәүләт вәкаләтләренең чоры**

Җирле үзидарә органнарына дәүләт вәкаләтләре чикләнмәгән чорга бирелә.

5 статья. **Җирле үзидарә органнарына тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен финанс белән тәэмин итү**

1. Җирле үзидарә органнарына тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен финанс белән тәэмин итү Татарстан Республикасы бюджетыннан муниципаль районнар һәм "Чаллы шәһәре" шәһәр округы бюджетларына бирелә торган субвенцияләр исәбеннән гамәлгә ашырыла.

2. Дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен җирле бюджетларга бирелә торган субвенцияләрнең гомуми күләмен билгеләү нормативларын исәпләү әлеге Законга кушымта нигезендә Дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен җирле бюджетларга бирелә торган субвенцияләрнең гомуми күләмен билгеләү нормативларын исәпләү методикасына таянып гамәлгә ашырыла.

3. Җирле бюджетларга дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен бирелә торган субвенцияләр күләме чираттагы финанс елына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы белән билгеләнә.

6 статья. **Дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда җирле үзидарә органнарының хокуклары һәм бурычлары**

1. Дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда җирле үзидарә органнары түбәндәгеләргә хокуклы:

1) дәүләт вәкаләтләре Татарстан Республикасы бюджетыннан җирле бюджетларга бирелә торган субвенцияләр исәбеннән финанслар белән тәэмин ителергә;

2) дәүләт вәкаләтләре тиешле матди ресурслар белән тәэмин ителергә;

3) муниципаль берәмлек уставы белән каралган очракларда һәм тәртиптә үзләренә тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен үзләренең матди ресурсларыннан һәм финанс чараларыннан өстәмә файдаланырга;

4) дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарында мәгълүмати, консультатив, оештыру һәм методик ярдәм алырга.

2. Дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда җирле үзидарә органнары түбәндәгеләрне үтәргә тиеш:

1) дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру эшчәнлеген башкару өчен махсус вәкаләтле җирле үзидарә органнарын һәм аларның вазыйфаи затларын билгеләргә;

2) законнарны, шулай ук дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының үз компетенцияләре чикләрендә кабул ителгән актларын үтәргә;

3) законнар нигезендә тиешенчә дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашырырга;

4) җирле үзидарә органнары тарафыннан дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелгән матди ресурсларның һәм финанс чараларының нәтиҗәле һәм рациональ файдаланылуын тәэмин итәргә;

5) дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга, әлеге максатларга бүлеп бирелгән матди ресурслардан һәм финанс чараларыннан файдалануга бәйле кирәкле мәгълүматны һәм документларны Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органнарына тапшырырга;

6) дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру һәм финанс чараларын тоту турындагы хисапларны Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органнарына тапшырырга;

7) Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органнарына дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны тикшереп торуда ярдәм күрсәтергә.

7 статья. **Җирле үзидарә органнары тарафыннан дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының хокуклары һәм бурычлары**

1. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары түбәндәге хокукларга ия:

1) дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча җирле үзидарә органнары эшчәнлеген үз компетенцияләре чикләрендә координацияләргә;

2) дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру барышында җирле үзидарә органнары яисә аларның вазыйфаи затлары тарафыннан җибәрелгән хокук бозуларны бетерү турында язма күрсәтмәләр бирергә;

3) җирле үзидарә органнарыннан аларның дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруына бәйле, шулай ук әлеге максатларга бирелгән матди ресурслардан һәм финанс чараларыннан файдалануы буенча кирәкле мәгълүматны һәм документларны билгеләнгән тәртиптә сорап алырга.

2. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары түбәндәгеләрне үтәргә тиеш:

1) дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен кирәкле матди ресурсларны һәм финанс чараларын җирле үзидарә органнарына тапшыруны тәэмин итәргә;

2) тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча җирле үзидарә органнарына мәгълүмати, консультатив, оештыру һәм методик ярдәм күрсәтергә;

3) Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең тиешле вәкаләтле органнары аша җирле үзидарә органнарының тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен башкаруны, әлеге максатларга бирелгән матди ресурслардан һәм финанс чараларыннан файдалануны тикшереп торуны гамәлгә ашырырга.

8 статья. **Дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру турында җирле үзидарә органнарының хисаплылык тәртибе**

Җирле үзидарә органнарына тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру турындагы хисаплар җирле үзидарә органнары тарафыннан хисап елыннан соң киләсе елның 15 гыйнварына кадәр ел саен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән рәвеш буенча Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең ветеринария эше өлкәсендә вәкаләтле органына тапшырыла.

9 статья. **Тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен җирле үзидарә органнары тарафыннан гамәлгә ашыруны тикшереп тору**

1. Җирле үзидарә органнарына тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны тикшереп тору түбәндәгеләр тарафыннан башкарыла:

1) Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең ветеринария эше өлкәсендә вәкаләтле органы – тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен җирле үзидарә органнары тарафыннан тиешенчә гамәлгә ашыру өлешендә түбәндәге рәвешләрдә:

а) дәүләт вәкаләтләрен башкару турында кирәкле документларны, хисапларны һәм мәгълүматны соратып алу;

б) дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча җирле үзидарә органнары эшчәнлегенә күрсәтелгән орган тарафыннан ел саен раслана торган план нигезендә, шулай ук кирәк булган саен планнан тыш күчмә тикшерүләр үткәрү;

2) Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең финанс сәясәте өлкәсендә вәкаләтле органы – дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен бирелгән финанс чараларының максатчан кулланылуы өлешендә түбәндәге рәвешләрдә:

а) дәүләт вәкаләтләрен башкару турында кирәкле документларны, хисапларны һәм мәгълүматны соратып алу;

б) дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру, шул исәптән элек соратып алынган документларны, хисапларны, мәгълүматны тикшерү нәтиҗәләре буенча, шулай ук законнар бозуда ачыкланган фактларга бәйле рәвештә җирле үзидарә органнары эшчәнлегенә кирәк булган саен күчмә тикшерүләр үткәрү;

в) хокук бозуларны бетерү һәм аларны кисәтү буенча кирәкле чаралар күрү;

3) Татарстан Республикасы милкендәге матди чараларны әлеге Законда каралган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны тәэмин итү өчен җирле үзидарә органнарына түләүсез файдалануга тапшырган очракта, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мөлкәт мөнәсәбәтләре өлкәсендә вәкаләтле органы – дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен җирле үзидарә органнарына тапшырылган дәүләт мөлкәтенең сакланылышы һәм тиешенчә файдаланылуы өлешендә түбәндәге рәвешләрдә:

а) дәүләт вәкаләтләрен башкару турында кирәкле документларны, хисапларны һәм мәгълүматны соратып алу;

б) дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру, шул исәптән элек соратып алынган документларны, хисапларны, мәгълүматны тикшерү нәтиҗәләре буенча, шулай ук

законнар бозуда ачыкланган фактларга бәйле рәвештә җирле үзидарә органнары эшчәнлегенә кирәк булган саен күчмә тикшерүләр үткәрү;

в) хокук бозуларны бетерү һәм аларны кисәтү буенча кирәкле чаралар күрү.

2. Җирле үзидарә органнары дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча законнардагы таләпләрне үтәмәгән яисә тиешенчә үтәмәгән очракта, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең ветеринария эше өлкәсендә вәкаләтле органы хокук бозулар ачыкланган көннән алып 10 көн эчендә аларны бетерү турында җирле үзидарә органнарына күрсәтмә җибәрә.

3. Ачыкланган хокук бозуларны бетерү турындагы күрсәтмәне кергән көненнән алып 10 көн эчендә карау мәҗбүри. Күрсәтмәне карау нәтиҗәләре турында Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең ветеринария эше өлкәсендә вәкаләтле органына кичекмәстән язма рәвештә хәбәр ителә.

10 статья. **Җирле үзидарә органнарының үзләренә тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруларын туктату шартлары һәм тәртибе**

1. Җирле үзидарә органнарының үзләренә бирелгән дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруларын туктату Татарстан Республикасы законы белән түбәндәге очракларда башкарыла:

1) дәүләт вәкаләтләрен җайга салу өлкәсендә гамәлдәге закон таләпләрен җирле үзидарә органнарының үтәмәве яисә тиешенчә үтәмәве;

2) законнар бозуларны бетерү турындагы күрсәтмәләрнең җирле үзидарә органнары һәм аларның вазыйфаи затлары тарафыннан үтәлмәве;

3) федераль законнарны яисә Татарстан Республикасы законнарын нәтиҗәдә җирле үзидарә органнарының үзләренә тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен башкару мөмкин булмаслык итеп үзгәртү.

2. Әлеге статьяның 1 өлешендә каралган очракларда Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең ветеринария эше өлкәсендә вәкаләтле органы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына җирле үзидарә органнарының дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруларын туктату турында тәкъдим һәм тиешле Татарстан Республикасы законы проектын кертә.

3. Җирле үзидарә органнарының үзләренә бирелгән дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруларын туктату файдаланылмаган финанс чараларын, шулай ук дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен тапшырылган матди чараларны кире кайтарып бирүгә китерә.

11 статья. **Йомгаклау нигезләмәләре**

1. Әлеге Закон нигезләмәләре, чираттагы финанс елына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законында җирле үзидарә органнары тарафыннан дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга субвенцияләр бирү каралган очракта, ел саен күрсәтелгән закон белән гамәлгә кертелә.

2. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары һәм Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары норматив хокукый актлары әлеге Законның үз көченә кергән көненнән алып өч ай эчендә әлеге Законга тәңгәлләштерелергә тиеш.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2012 елның 13 гыйнвары
№ 9-ТРЗ

"Муниципаль районнарның һәм
"Чаллы шәһәре" шәһәр округының
җирле үзидарә органнарына хайваннар
чирләрен кисәтү һәм бетерү,
аларны дәвалау, кеше һәм хайваннар өчен
уртак чирләрдән халыкны яклау чараларын
үткәрүне оештыру өлкәсендә
Татарстан Республикасының
аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында"
Татарстан Республикасы Законына
кушымта

## ХАЙВАННАР ЧИРЛӘРЕН КИСӘТҮ ҺӘМ БЕТЕРҮ, АЛАРНЫ ДӘВАЛАУ, КЕШЕ ҺӘМ ХАЙВАННАР ӨЧЕН УРТАК ЧИРЛӘРДӘН ХАЛЫКНЫ ЯКЛАУ ЧАРАЛАРЫН ҮТКӘРҮНЕ ОЕШТЫРУ ӨЛКӘСЕНДӘ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ АЕРЫМ ДӘҮЛӘТ ВӘКАЛӘТЛӘРЕН ГАМӘЛГӘ АШЫРУ ӨЧЕН ҖИРЛЕ БЮДЖЕТЛАРГА БИРЕЛӘ ТОРГАН СУБВЕНЦИЯЛӘРНЕҢ ГОМУМИ КҮЛӘМЕН БИЛГЕЛӘҮ НОРМАТИВЛАРЫН ИСӘПЛӘҮ МЕТОДИКАСЫ

1. Әлеге Методика Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә эшләнде.

2. Методика хайваннар чирләрен кисәтү һәм бетерү, аларны дәвалау, кеше һәм хайваннар өчен уртак чирләрдән халыкны яклау чараларын үткәрүне (алга таба – мал-туарның түләмә чире каберлекләрен һәм биотермик чокырларны карап тоту, аларның иминлеген тәэмин итү чараларын күрү, биотермик чокырларны консервацияләү) оештыру өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен җирле бюджетларга Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә торган субвенцияләрнең күләмен исәпләү тәртибен билгеләү өчен каралган.

3. Мал-туарның түләмә чире каберлекләрен һәм биотермик чокырларны карап тоту, аларның иминлеген тәэмин итү чараларын күрү, биотермик чокырларны консервацияләү өчен муниципаль берәмлекләр бюджетларына бирелә торган субвенцияләрнең гомуми күләме түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$S = \underset{i=1}{\overset{m}{SUM}} HP_i ,$$

монда:

*S* – муниципаль берәмлекләр бюджетларына дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга субвенцияләрнең гомуми күләме;

*HPi* – дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга i-муниципаль берәмлеге бюджетына субвенцияләр күләме;

m – Татарстан Республикасында дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен бюджетларына субвенцияләр бирелә торган муниципаль берәмлекләр саны.

4. Дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга i-муниципаль берәмлеге бюджетына субвенцияләр күләме мал-туарның түләмә чире каберлекләрен һәм биотермик чокырларны карап тоту, аларның иминлеген тәэмин итү чараларын күрү, биотермик чокырларны консервацияләү өчен норматив чыгымнардан чыгып билгеләнә:

$$HP_i = HP_{БЯ_i} + HP_{СС_i},$$

монда:

$HP_i$ – дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга i-муниципаль берәмлеге бюджетына субвенцияләр күләме;

$HP_{БЯ_i}$ – i-муниципаль берәмлеге буенча биотермик чокырларны карап тоту, аларның куркынычсызлыгын һәм аларны консервацияләүне тәэмин итү чараларын күрү өчен норматив чыгымнар;

$HP_{СС_i}$ – i-муниципаль берәмлеге буенча мал-туарның түләмә чире каберлекләрен карап тоту, аларның иминлеген тәэмин итү чараларын күрү өчен норматив чыгымнар.

5. Мал-туарның түләмә чире каберлекләрен һәм биотермик чокырларны карап тоту, аларның иминлеген тәэмин итү чараларын күрү, биотермик чокырларны консервацияләү чыгымнарына түбәндәгеләр кертелә:

1) биотермик чокыр өчен:

биотермик чокыр конструкциясен дезинфекцияләү;

белгечне кирәкле инвентарь инструментлар һәм махсуслаштырылган кием белән тәэмин итү;

биотермик чокыр конструкциясенә агымдагы ремонтны, территория җыештыруны кертеп, биотермик чокырга хезмәт күрсәтү, аны эксплуатацияләү һәм консервацияләү;

2) мал-туарның түләмә чире каберлеге өчен – мал-туарның түләмә чире каберлегенә агымдагы ремонтны, территория җыештыруны кертеп, мал-туарның түләмә чире каберлегенә хезмәт күрсәтү.

6. Биотермик чокыр конструкциясен дезинфекцияләүгә чыгымнар Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең ветеринария эше өлкәсендә вәкаләтле органы тарафыннан расланган бәяләр нигезендә, авыл хуҗалыгы оешмалары буенча бинаның 1000 кв. метрына бәяләрдән чыгып, товарлар һәм халыкка хезмәт күрсәтүләр бәясе индексын исәпкә алып исәпләп чыгарыла.

7. Белгечне кирәкле инвентарь инструментлар һәм махсуслаштырылган кием белән тәэмин итүгә чыгымнар ветеринария хезмәте учреждениеләрен карап тотуга Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты норматив хокукый актлары белән расланган натураль чыгымнар нормаларыннан (җиңел инвентарь һәм обмундирование чыгымы нормасы, дезинфекция препаратлары чыгымы нормасы, биналарны җыештыруга юу матдәләре чыгымы нормасы һәм башкалар) чыгып исәпләнә.

8. Мал-туарның түләмә чире каберлекләренә хезмәт күрсәтү чыгымнары һәм биотермик чокырларга хезмәт күрсәтү, аларны эксплуатацияләү, консервацияләү чыгымнары, тышкы төзекләндерү объектларын ремонтлауга һәм карап тотуга Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты норматив хокукый актлары белән расланган уртача еллык тотылган акчалар нормасыннан чыгып, төзелеш-монтаж эшләре бәясенең үзгәрү индексын кулланып исәпләнә.

9. I-муниципаль берәмлегендә мал-туарның түләмә чире каберлекләрен һәм биотермик чокырларны карап тоту, аларның иминлеген тәэмин итү чараларын күрү, биотермик чокырларны консервацияләү өчен норматив чыгымнар күләме түбәндәге формулалар буенча билгеләнә:

1) биотермик чокырлар өчен:

$$HP_{БЯ_i} = \underset{j=1}{\overset{n}{SUM}}\left(НД^i_j + НИ^i_j + НЭ^i_j\right),$$

монда:

$НР_{БЯ_i}$ – i-муниципаль берәмлеге буенча биотермик чокырларны карап тоту, аларның куркынычсызлыгын һәм аларны консервацияләүне тәэмин итү чараларын күрү өчен норматив чыгымнар;

$НД^i_j$ – i-муниципаль берәмлеге буенча j-биотермик чокырын дезинфекцияләүгә норматив чыгымнар;

$НИ^i_j$ – i-муниципаль берәмлеге буенча j-биотермик чокыр инвентарена норматив чыгымнар;

$НЭ^i_j$ – i-муниципаль берәмлеге буенча j-биотермик чокырына хезмәт күрсәтү, аны эксплуатацияләүгә һәм консервацияләүгә норматив чыгымнар;

n – i-муниципаль берәмлегендә биотермик чокырлар саны;

2) мал-туарның түләмә чире каберлекләре өчен:

$$HP_{CC_i} = \underset{j=1}{\overset{n}{SUM}} HO^i_j,$$

монда:

$НР_{СС_i}$ – i-муниципаль берәмлеге буенча мал-туарның түләмә чире каберлекләрен карап тоту, аларның иминлеген тәэмин итү чараларын күрү өчен норматив чыгымнар;

$НО^i_j$ – i-муниципаль берәмлеге буенча мал-туарның түләмә чире j-каберлегенә хезмәт күрсәтү өчен норматив чыгымнар;

n – i-муниципаль берәмлегендә мал-туарның түләмә чире каберлекләре саны.